СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРЖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.04.2023 Әгерҗе шәһәре № 28-8

Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан адреслау объектларына адреслар бирү, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү һәм җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирү, адреслар һәм исемнәрне үзгәртү, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыруны гамәлгә турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре советларының Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына адреслау объектларына адреслар бирү, урам-юл челтәре элементларына исемнәр бирү һәм җирлек чикләрендә планлаштырылган структура элементларына исемнәр бирү, адресларны һәм исемнәрне үзгәртү, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыру турындагы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына адреслау объектларына адреслар бирү, урам-юл челтәре элементларына исем бирү һәм җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исем бирү, адресларны һәм исемнәрне үзгәртү, мәгълүматны дәүләт адреслар реестрында урнаштыру буенча Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен кабул итәргә.

2. Әлеге карар нигезендә, Әгерҗе муниципаль районыныц җирле үзидарә органнары белән Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны кабул итү-тапшыру турында килешү төзергә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе урынбасары,
Муниципаль район Башлыгы урынбасары И.И. Ямалиев